ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2018 Казан ш. № 3-7/э

«Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Электр челтәрләре компаниясе» ачык акционер җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара хисаплашулар өчен электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә 2019 – 2021 елларга индивидуаль тарифлар билгеләү турында

"Электр энергетикасы турында" 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Электр энергетикасында җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында" 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең "Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салына торган тарифларны һәм бәяләрне исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм "Электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә тиешле тулаем табышны озак вакытка индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Электр челтәрләре компаниясе» ачык акционер җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара хисаплашулар өчен электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2021 елның 31 декабренә кадәр индивидуаль тарифларны, календарь бүленештә күрсәтеп, әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар территориаль челтәр оешма эшчәнлеген җайга салуның озак вакытка каралган параметрларына нигезләнеп билгеләнә торган «Экострой Инжиниринг»

җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 - 2021 елларга җайга салуның озак вакытка исәпләнгән параметрларын әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

3. 2019 - 2021 елларга «Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кирәкле тулаем табышын (югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча) әлеге карарга 3 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 7 декабрендәге 3-7/э
номерлы карарына 1 нче кушымта

«Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм
«Электр челтәрләре компаниясе» ачык акционер җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара хисаплашулар өчен
электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә индивидуаль тарифлар
2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2021 елның 31 декабренә кадәр календарь бүленеш белән

<table>
<tr><th rowspan="4">т/б<br>№</th><th rowspan="4">Челтәр оешмаларның исеме</th><th rowspan="4">Ел</th><th colspan="3">1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр</th><th colspan="3">1 июльдән 31 декабрьгә кадәр</th></tr>
<tr><th colspan="2">Ике ставкалы тариф</th><th rowspan="2">Бер ставкалы тариф</th><th colspan="2">Ике ставкалы тариф</th><th rowspan="2">Бер ставкалы тариф</th></tr>
<tr><th>электр челтәрләрен карап тотуга ставка</th><th>технологик чыгымнар (югалтулар) өчен түләүгә ставка</th><th>электр челтәрләрен карап тотуга ставка</th><th>технологик чыгымнар (югалтулар) өчен түләүгә ставка</th></tr>
<tr><th>сум/МВт.ай</th><th>сум/МВт.сәг.</th><th>сум/кВт.сәг.</th><th>сум/МВт.ай</th><th>сум/МВт.сәг.</th><th>сум/кВт.сәг.</th></tr>
<tr><td rowspan="3">1</td><td rowspan="3">«Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте - «Электр челтәрләре компаниясе» ачык акционер җәмгыяте</td><td>2019</td><td>332 796,41</td><td>269,83</td><td>1,15727</td><td>332 796,41</td><td>288,44</td><td>1,17589</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>348 309,31</td><td>288,57</td><td>1,21788</td><td>348 309,31</td><td>297,04</td><td>1,22575</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>364 331,54</td><td>297,04</td><td>1,26847</td><td>364 331,54</td><td>305,95</td><td>1,27738</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 7 декабрендәге 3-7/э
номерлы карарына 2 нче кушымта

## Электр энергиясен тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә тарифлар территориаль челтәр оешманың эшчәнлеген җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары нигезендә билгеләнә торган «Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 - 2021 елларга җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| т/б № | Татарстан Республикасында челтәр оешманың исеме | Ел | Тикшерелергә тиешле чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Тикшерелергә тиешле чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Тикшерелергә тиешле чыгымнарның активлар саны буенча бәйлелек коэффициенты | Электр энергиясенең технологик чыгымы (югалту) зурлыгы (электр энергиясен электр челтәрләре буенча тапшырганда аны югалту дәрәҗәсе) | | | | Сатыла торган товарларның (хезмәтләр күрсәтүнең) ышанычлылык дәрәҗәсе | Сатыла торган товарларның (хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфат дәрәҗәсе | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | Хезмәтләр күрсәтелүдән файдаланучыларга хезмәт күрсәтү сыйфаты дәрәҗәсе күрсәткече | Башкарыла торган технологик тоташтыруның сыйфаты дәрәҗәсе күрсәткече |
| | | | млн.сум | % | % | ВН | СН-I | СН-II | НН | | | |
| 1 | «Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2019 | 8,09273 | 1 | 75 | | | 5,64 | 10,49 | 0,022 | 1 | 1 |
| | | 2020 | X | 1 | 75 | | | 5,64 | 10,49 | 0,022 | 1 | 1 |
| | | 2021 | X | 1 | 75 | | | 5,64 | 10,49 | 0,022 | 1 | 1 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 7 декабрендәге 3-7/э
номерлы карарына 3 нче кушымта

«Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең
кирәкле тулаем табышы (югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча)
2019 - 2021 елларга

| т/б № | Татарстан Республикасында челтәр оешманың исеме | Ел | Челтәр оешманың югалтулар өчен түләүләр исәпкә алынмаган кирәкле тулаем табышы |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 1 | «Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2019 | 13 832,56 |
| | | 2020 | 14 478,52 |
| | | 2021 | 15 144,53 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге